РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

29.12.2025

№1134-п

2026 елда халыкка күрсәтелә торган
торак хезмәтләренә тарифлар
турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 03 апрелендәге 290 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Сабин муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 гыйнварыннан торак урыныннан файдаланган өчен түләүнең чик күләмен (наем өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы буенча 2026 елга халык өчен, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен расларга һәм гамәлгә кертергә. (кушымтада бирелә).
2. Әлеге карарны «Саба таннары» район газетасында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары - икътисад бүлеге начальнигы М. М. Баһмановка йөкләргә.

Җитәкче М.Р.Кәримов

Саба муниципаль районының
"___" декабрь 2025 ел, №______
Башкарма комитет карары белән
РАСЛАНДЫ

**Торак урыныннан файдаланган өчен түләү күләме (наем өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләме, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы буенча 2026 елга халык өчен, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме**

| № т/б | Түләү исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | 2026 елның 1 гыйнварыннан хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф , сум. | 2026 елның 1 июленнән хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф, сум. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 3,55 | 3,55 |
| 2 | Торак бинага агымдагы ремонт | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 3,36 | 3,66 |
| 3 | Ишегалдын тәртиптә тоту (җәйге чорда үләннәрне һәм чүп үләннәрен чабу) | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 0,51 | 0,56 |
| 4 | Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту: | | | |
| | суүткәргеч-канализация челтәрләре | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 2,71 | 2,71 |
| | суүткәргеч челтәрләре | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 2,20 | 2,44 |
| | үзәк җылыту челтәрләре | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 2,85 | 3,13 |
| | электр белән тәэмин итү челтәрләре | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 1,38 | 1,51 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | вентиляция каналларын тикшерү (карау) | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 0,24 | 0,26 |
| | морҗа системаларын тикшерү (карап чыгу) | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 0,24 | 0,26 |
| | домофонга хезмәт күрсәтү | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 0,45 | 0,49 |
| 5 | Фасад газүткәргечләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 0,45 | 0,49 |
| 6 | 30 елдан артык булган йортларның газ челтәрләрен техник диагностикалау өчен түләү | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 0,64 | 0,64 |
| 7 | Сыек көнкүреш калдыкларын чыгарган өчен тарифның иң чик ставкасы | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 16,35 | 18,80 |
| 8 | Торак урынны арендага алган өчен түләүнең иң чик ставкасы | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 31,53 | 37,29 |